ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423750, Уразай авылы, Үзәк ур.,
2 нче йорт. Тел 3-44-62
Email: : uraz-akt-2@yandex.ru

УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423750, дер.Уразаево, ул. Центральная ,
дом 4. Тел 3-44-62
Email: uraz-akt-2@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«29» сентябрь 2025 ел　　　　№15

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 07 апрелендәге 7 номерлы «Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 ел 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 4_1 өлеш өстәргә:

«4_1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре"бүлегендә урнаштырырга.

Уразай авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　Г.С.Шаймарданова